**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Олы Карамалы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

08 нче декабрь 2021 ел № 4

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 нче елның 08 нче декабрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «2022 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясе, Олы Карамалы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, ташламалы категорияләрдән тыш (беренче төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлар), Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясендә яшәүче, җирлек территориясендә тавыш бирергә хокукы булган, яшәү урыны буенча турыдан-туры теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Олы Кармалы авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Олы Кармалы авылында юлларны кардан чистарту, тигезләү (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Җәйге чорда Олы Кармалы авылы территориясен чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 89 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 62 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 58 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 4 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге составына керүче Олы Карамалы авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «2022 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясе, Олы Карамалы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, ташламалы категориялардән тыш (беренче төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлар), Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясендә яшәүче, җирлек территориясендә тавыш бирергә хокукы булган, яшәү урыны буенча турыдан-туры теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Олы Кармалы авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Олы Кармалы авылында юлларны кардан чистарту, тигезләү (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Җәйге чорда Олы Кармалы авылы территориясен чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)» соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. 2022 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясе, Олы Карамалы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, ташламалы категориялардән тыш (беренче төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлар), Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге территориясендә яшәүче, җирлек территориясендә тавыш бирергә хокукы булган, яшәү урыны буенча турыдан-туры теркәлгән, һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:

- Олы Кармалы авыл эчендәге юлларны ремонтлау (таш сатып алу, ташу, вак таш җәю, ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Олы Кармалы авылында юлларны кардан чистарту, тигезләү (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Җәйге чорда Олы Кармалы авылы территориясен чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Карамалы авылы, Үзәк урамы, 4;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Бәрлегуҗа авылы, Тукай урамы, 16, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Олы Карамалы авыл җирлеге
башлыгы: Э.И.Байдамшин